

Торле юллар белән халыкны, бигрәк тә олкән яшьтәге кешеләрне алдау, талау очраклары ешая. Мошенниклык гамәлләре турында даими искәртеп торуга карамастан, кызганычка каршы, алар кармагына эләгvчеләр һаман очрап тора. Узган ел белән чагыштырганда шундый жинаять очрагы якынча 60% арткан.
Россиядә банкоматлар белән мошенниклыкнын яна торе барлыкка килгән.
Мошенниклар банкоматка салу очен ялган акчага махсус тасма ябыштыра һәм икенче банкоматтан чын акча ала башлаган. Бу турыда Россия Генераль прокуратурасы вәкиле Елена Малыкка сылтама белән ТАСС хәбәр итә.

«Ялган акча ясаунын яна торе ачыкланды, акча купюраларын банкомат очен махсус ясыйлар», - дигән Елена Малык.
Мошенниклар ялган купюрага махсус тасма ябыштыра, бу банкомат аны чын купюра дип кабул итсен очен эшләнелә. Аннары алар керткән сумманы башка банкоматтан чын акча белән ала. Генераль прокуратура вәкиле сvзләренчә, бу жинаятьләр банкоматта акча беткәннән сон һәм янадан санаганда ачыклана.
Быел Россиядә банк олкәсендә барлыгы 18,8 мен жинаять теркәлгән. Икътисади жинаять аркасында 154 миллиард сумнан артык зыян килгән.
Мордовиядә яшәvче 27 яшьлек хатын-кыз «Лайк» куйгач, 255 мен сум акча югалткан, дип хәбәр итә mordovmedia.ru сайты. Жирле хатын-кыз полициягә морәжәгать иткән. Ул мессенджерда остәмә акча тәкъдим итv турында хәбәр алгач, мошенниклар корбаны булуын хәбәр итә. Кызга бәяләмәләр язу һәм «лайклар» куюдан акча эшләргә тәкъдим итәләр. Танылган интернет-броньлау сайтындагы кунакханәләрне мактарга кирәк булган.
Кызга тvләv очен карточка мәгъ-лvматларын кvрсәтер очен счет кертергә кирәк булган. Моннан тыш, шәхси кабинет счетына остәмә процентлар алу очен шәхси акчалар куярга кирәккән. Кыз ышана һәм эшкә керешә. Ул хәтта берничә сәгать эчендә 11 мен сум акча эшләгән һәм шуннан сон vз акчасын исәп-хисапка керткән. Шәхси кабинетта кызнын 474 мен сум акча эшләве турында хәбәр килә. Эш хакын алу очен 306 мен сум акча кертергә кирәк була. Кызнын ботен суммасы да булмаган һәм ул азрак керткән. Шулай итеп ул 255 мен сумнан артык акча югалта.